КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 июль г.Казань № 715

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август, 761 нче карары белән расланган Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август, 761 нче карары белән расланган Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«грантлар алучыларның алынган грант күләме чикләрендә чыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү турындагы мөрәҗәгатьләрен карап тикшерә.»;

6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Заявкалар Министрлык тарафыннан Система аша кабул ителә.

Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), заявкалар кабул ителә башланганга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, конкурс үткәрү турында белдерү урнаштыра:

конкурс үткәрү срокларын;

заявкалар бирә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул конкурс үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 7.8 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 4.2 пункты нигезендә конкурста катнашучыларга карата таләпләрне һәм конкурста катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 5.1 – 5.3 пунктлары нигезендә конкурста катнашучылар тарафыннан бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 6.4 – 6.15 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләрен;

конкурста катнашучыларга конкурс үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатма бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

конкурста җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан Килешүгә имза куелырга тиешле срокны;

конкурста җиңүчене (җиңүчеләрне) Килешү төзүдән читләшкән дип тану шартларын;

конкурс нәтиҗәләрен бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру датасын (ул конкурста җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән соңрак була алмый);

бу Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә сайлап алу критерийларын һәм бу Тәртипнең 6.7 пункты нигезендә бәяләү критерийларын.»;

7.2 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алучының, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешма-

ларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алучының Килешү йөкләмәләрен үтәү максатларында төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы турындагы нигезләмәләрне кертү буенча йөкләмәсе;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен грант алучының җаваплылыгы, шул исәптән грант алучы тарафыннан грант бирү тәртибен һәм шартларын бозган өчен (кирәк булганда кулланыла торган) штраф санкцияләре;

8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Грант алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 енннән дә соңга калмыйча, дүртенче квартал өчен – грант бирелгән елдан соң килә торган елның 10 декабреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып грант торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында һәм грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында Министрлыкка хисаплар кертә.»;

8.3 пунктта:

икенче абзацта «шартлар» сүзен «шартлар һәм тәртип» сүзләренә, «нәтиҗәләренә ирешү» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«A = \left(\sum_{i=1}^{3}\left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right) \times X\right) \times V,»;$$

8.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.5. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Грант бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешүдән һәм грант бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

8.6 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 4.2 пунктындагы өченче абзацының һәм 5.1 пунктындагы дүртенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы алтынчы абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин